СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.06.2021 г.Зеленодольск № 42

2020 елның 7 сентябрендәге 301 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексына, 2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 294-ФЗ номерлы Федераль законга, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск шәһәре Советы, **карар итте:**

1. 2020 елның 7 сентябрендәге 301 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә (алга таба-Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1) Нигезләмәнең 5.2 пунктындагы 1 пунктчасын төшереп калдырырга.

1.2) Нигезләмәнең 5.23 пунктындагы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.32. Документлар буенча тикшерү уздырганда муниципаль торак контроле органы юридик заттан, индивидуаль эшкуардан документлар тикшерү предметына карамаган белешмәләрне һәм документларны, шулай ук әлеге орган дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) башка органнарыннан,

муниципаль контроль органнарыннан алырга мөмкин булган белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуклы түгел».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск шәһәре Хакиме,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА ИНН 1648017849 КПП 164801001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ